**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422619 с. Малая Елга
ул.Советская,58
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422619Кече Елга авылы,
Совет урамы, 58нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

---

**2022 елның 2 июне** **9 номер**

# КАРАР

## Гарантияле тәэминатчыны билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районы территориясендә үзәкләштерелгән, тиешле һәм өзлексез су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызуны оештыру максатында карар бирәм:

1. Иң күп абонентлары булган "РСК «Инженерлык технологияләре»ҖЧҖ үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системасына, әлеге ресурслар белән тәэмин итүче буларак, гарантияле оешма статусы бирергә;
2. Лаеш муниципаль районы Кече Елга авылы территориясен (Шуран авылы һәм Полянка авылы) гарантияләүче оешма эшчәнлеге зонасы итеп билгеләргә;
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам..

**Кече Елга авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.З.Хисамов**